**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау системасы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне комплекслы мониторинглау системасын камилләштерү һәм дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау системасы турында» 2015 елның 25 апрелендәге ПУ-414 номерлы (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1095 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 5 пунктта «Татарстан Республикасы прокуратурасы,» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе,» сүзләрен өстәргә;

б) Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау системасы турында нигезләмәнең 8 пунктында:

түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе (килешү буенча);»;

сигезенче-егерме беренче абзацларны тиешенчә тугызынчы-егерме икенче абзацлар дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 27 февраль
№ ПУ-215